**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №110-18 «18» апрель 2017 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 23 гыйнварындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә (31.10.2008 №217-30, 15.03.2012 №121-18, 26.04.2013 №228-34, 29.01.2014 №284-40, 19.03.2015 №351-51 карарлар редакциясендә)

Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә,

Азнакай район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 23 гыйнварындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә (31.10.2008 №217-30, 15.03.2012 №121-18, 26.04.2013 №228-34, 29.01.2014 №284-40, 19.03.2015 №351-51 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктта:

1.1.1. егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук муниципаль район территориясендә террорчылык һәм экстремизм күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашу:

террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышлары зыяннарын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү өлкәсендә муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

муниципаль берәмлекләрдә террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату буенча, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәүне формалаштыру буенча, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү юлы белән, мәгълүмати-пропаганда чараларын оештыру һәм үткәрү;

терроризмны профилактикалау, шулай ук аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органнары тарафыннан оештырыла торган чараларда катнашу;

муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү;

террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнарына җибәрү;

террорчылыкны профилактикалауда, шулай ук аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) бетерүдә катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»;

1.1.2. утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Азнакай муниципаль районы территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, Азнакай муниципаль районының рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;".

1.2. егерме бишенче – кырык бишенче абзацларны тиешенчә утыз беренче – илле беренче абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин